**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**от «31» октября 2025г.** **№ 1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге Уставы белән җыенның йомгаклау беркетмәсе төзелде» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең җерҗе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1,2,3 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларын, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнарны һәм алынган акчаларны мәсьәләне хәл итүгә юнәлтеп:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Молодежная урамында вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу)

«РИЗА» « КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 343 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 268.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 255, «КАРШЫ» позициясе өчен 13 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Әгерҗе торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре–гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең Авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1,2,3 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Кораллы Көчләрдә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда үзара салым кертүгә 600 сум күләмендә ризамы? Россия Федерациясе көчләрендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп:

- - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Молодежная урамында вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу) - кабул ителгәннәр тарафыннан.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әгерже авылы, Г.Ахметова урамы, 1 йорт адресы буенча, Әгерже авылы, С.Хаким урамы, урам чатында, Әгерже авылы, Г.Гафиятуллина урамы, 10 йорт белән 23а йорты арасында урнашкан Әгерҗе авыл җирлеге мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерже авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әгерже авыл җирлеге башлыгы

Ә.Г. Мирзаһитова